DOI: 10.26907/2311-2042-2022-19-2-173-181

# THE EMINENT SCHOLAR OF LITERATURE AZAT GILMUULLOVICH AKHMADULLIN

**Flera Sagitovna Sayfulina,**
Kazan Federal University,
18 Kremlyovskaya Str., Kazan, 420008, Russian Federation,
fsaifulina@mail.ru



**Akhmadullin Azat Gilmullovich** (10.13.1932–12.08.2021) was a literary critic, theater connoisseur, art critic and a public figure.

He graduated from Kazan University in 1956 and began his teaching career at the Tobolsk Pedagogical Institute (1956–1958). Later, he worked for the Radio Committee of the TASSR (1961–1963). A. Akhmadullin defended his Ph.D. thesis in 1964, his doctoral dissertation in 1984, and in 1988 he became a professor, then a corresponding member of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan (1994). In 1963–1981, he worked at the Institute of Language, Literature and History (now the Institute of Language, Literature and Art), from 1972 he was a deputy director.

From 1981 he was a professor of Kazan University and until 1999 he headed the Department of Tatar Literature. At the same time, in 1999–2004, he taught a course at Kazan Pedagogical University, in 2000–2004 he was the Head of the Department of Tatar Literature.

**Әхмәдуллин Азат Гыйльмулла улы** (13.10.1932-08.12.2021) – әдәбият галиме, театр белгече, тәнкыйтьче, җәмәгать эшлеклесе.

Казан университетын 1956 елда тәмамлагач, Тубыл (Тобольск) дәүләт педагогия институтында укыта (1956 - 1958). ТАССР Радиокомитетында 1961 - 1963 елларда эшли. А. Әхмәдуллин 1964 елда кандидатлык, 1987 елда докторлык диссертациясен яклый һәм 1988 елда филология фәннәре докторы гыйльми дәрәҗәсенә һәм профессор вазифасына ия була. ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1994). 1963-1981 елларда СССР Фәннәр Академиясенең Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм тарих институтында (хәзер: Тел, әдәбият һәм сәнгать институты) эшли. 1972дән директор урынбасары. 1981 - 1999 елларда Казан дәүләт университетында, 2000 - 2004 елларда, төп эш урыныннан аерылмыйча, Казан дәүләт педагогия университетында татар әдәбияты

**Ахмадуллин Азат Гильмуллович** (13.10.1932–08.12.2021) – литературовед, знаток театра, критик, общественный деятель.

Выпускник Казанского университета (1956). Преподавал в Тобольском педагогическом институте (1956–1958). Работал в Радиокомитете ТАССР (1961–1963). Защитил кандидатскую диссертацию в 1964 г., докторскую диссертацию – в 1984 г., в 1988 г. получил звание профессора. Член-корреспондент АН РТ (1994). В 1963–1981 гг. работал в Институте языка, литературы и истории (ныне Институт языка, литературы и искусства), с 1972 г. – заместитель директора.

С 1981 г. профессор Казанского университета, до 1999 г. заведующий кафедрой татарской литературы. Одновременно, в 1999–2004 гг., преподавал в Казанском педагогическом университете, в 2000–2004 гг. – заведующий кафедрой татарской литературы. В 2000–2012 гг. – профессор Казанского федерального университета.

From 1974 he was a member of the Union of Writers of the Republic of Tatarstan.

His scientific interests included the history and theory of Tatar drama, stage art, criticism, theory and methodology of literature, and methods of teaching literature.

Azat Akhmadullin was an Honored Worker of Arts of the TASSR (1982), Honored Worker of Science of the Republic of Tatarstan (2002), laureate of the International Prize named after Kul Gali, laureate of the J. Validi Prize of the Union of Writers of the Republic of Tatarstan, laureate of the K. Nasyri Prize of the Ministry of Education and Science of the Republic of Tatarstan, Honored Worker of Higher Professional Education, Honored Professor of Kazan University and a laureate of the State Prize of the Republic of Tatarstan (2017).

кафедрасы мөдире вазифасын башкара. 2000 – 2012 елларда Казан федераль университеты профессоры.

1974 елдан ТР Язучылар берлеге әгъзасы.

Татар драматургиясе тарихы һәм теориясе, сәхнә сәнгате, тәнкыйть, әдәбият теориясе һәм методологиясе, татар әдәбиятын укыту методикасы гыйльми эшчәнлегенең төп тармакларын билгели.

ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1982), ТРның атказанган фән эшлеклесе (2002), Россия Гуманитар фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы, Кол Гали исемендәге Халыкара бүләк лауреаты (2004), Казан университетының атказанган профессоры, ТРның Дәүләт премиясе лауреаты (2017), күпсанлы мактау грамоталары һәм премияләр иясе

С 1974 г. член Союза писателей РТ.

Основные направления научной деятельности – история и теория татарской драматургии, сценическое искусство, критика, теория литературы и методология, методика преподавания литературы.

Заслуженный деятель искусств ТАССР (1982), заслуженный деятель науки РТ (2002), лауреат международной премии им. Кул Гали, лауреат премии Дж. Валиди Союза писателей РТ, лауреат премии им. К. Насыйри Министерства образования и науки Республики Татарстан, почетный работник высшего профессионального образования, почетный профессор Казанского университета, лауреат Государственной премии РТ (2017).

Azat Gilmullovich Akhmadullin (1932–2021) was a literary critic, stage art expert and critic, the founder of the conceptual studies of the Tatar drama history and a teacher-methodologist who created his own scientific school and trend in Tatar literary criticism.

Azat Akhmadullin was born in the village of Bogatye Saby, the Sabinsky District of Tatarstan, on October 13, 1932. After graduating from high school, he taught physics and mathematics for a year at a seven-year school in the village of Shekshi. In 1951–1956, he received higher education at the Department of the Tatar Language and Literature of Kazan State University, from which he graduated with honors. For some time he worked as an editor in the editorial office of scientific and technical literature of the Tatar Book Publishing House.

He began his teaching career at the Tobolsk State Pedagogical Institute of the Tyumen Region, where he taught a course in 1956–1958. After working for two years in the system of higher education, Azat Akhmadullin returned to Kazan with a key decision to link his future life with literature. In 1958–1961, he studied at the graduate school of the Kazan branch of the USSR Academy of Sciences, after which he worked as the editor-in-chief of the Department of Literary and Artistic Broadcasting in the Tatar Radio Committee.

The scientific and pedagogical activities of Azat Akhmadullin were mainly aimed at the development of Tatar science and the preparation of national personnel in three republican organizations: the Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov of the Science Academy, Kazan State University and the Kazan State Pedagogical Institute.

A. Akhmadullin began his scientific research in 1963 at the Institute of Language, Literature and History (now: Language, Literature and Art) named after G. Ibragimov as a junior researcher. In 1964, he defended his Ph.D. thesis “Dramaturgy of Fathi Burnash” [1] under the scientific supervision of M. Gainullin and continued his work as a senior researcher. Here, the young scientist showed a talent for organising scientific work: from 1965 he worked as the scientific secretary of the Institute, in 1972 he became deputy director of the Institute responsible for scientific work.

In 1981, A. Akhmadullin was offered the position of the head of the Tatar Literature Department at Kazan State University, where he worked until 1999. From 2000 until his retirement in 2012, he was professor in the Department of Tatar Literature at Kazan State University (since 2011 it has been Kazan Federal University). In 1999–2004, simultaneously with teaching at Kazan Pedagogical University, he headed the Department of Tatar Literature in 2000–2004.

Adhering to the chosen scientific trend, Azat Akhmadullin defended his doctoral dissertation, devoted to the study of the development stages and

features of Tatar dramaturgy [2], at the Kazakhstan (Alma-Ata) Academy of Sciences in 1987; in 1988 he received the academic title of professor. In 1994, he was elected a corresponding member of the Tatarstan Republic Academy of Sciences.

A. Akhmadullin is rightfully considered to be the founder of the new scientific trend in the Tatar performing arts studies. The main scientific works of the scholar are devoted to a systemic study of the Tatar drama development on a conceptual basis. The research, which began with a monographic study of the outstanding playwright Fathi Burnash's work, led the scholar to literary criticism. "Every creative person unites his literary and scientific activity into one entity", writes T. Gilyazov. "Two complementary scientific trends of this intellectual activity can be distinguished. One of them is the study of F. Burnash's work, the other is Tatar dramaturgy" [3, p. 198]. Starting with this work, Azat Akhmadullin had come a long way, consisting of scientific discoveries, before he became a famous Tatar literary critic who made great contributions to the study of the Tatar literature history. The scholar repeatedly returned to F. Burnash's works, written in the 1940s, he achieved outstanding results studying his creative work and returned to literature the name of a person with a difficult fate, the author who carried out versatile activities in the field of dramaturgy, poetry, prose, journalism and translation [4], [5].

Numerous scientific articles of the scholar, devoted to topical issues of the Tatar theatrical art development in the 1960–1980s, were published in separate collections [6], [7]. Innovations in the work of playwrights in this particular genre of literature, the methods for the stage embodiment of a modern hero, the authenticity of life and its representation in a literary work and the views on such topical issues as stage genres allow us to imagine the qualitative development of the dramaturgy in that era.

In the monograph "Kunelne uyatir: khezerge tatar dramaturgiyasi" ("Awakening Our Hearts: Modern Tatar Dramaturgy"), published at the beginning of the 21st century (2007) [8], the researcher studies Tatar dramaturgy of the second half of the 20th century in a broad sense, considering national stage art as an integral process. In this major work, the author proves with convincing evidence that works, revealing the essence of the Soviet society developments and reflecting the artistic authenticity trend, appeared back in the 1960s and 1970s.

A. Akhmadullin, highlighting the trend of "the problem of finding a hero" that formed in the dramaturgy during the difficult period of "Stagnation', exemplifies it with creative searches and individual findings in the works of outstanding playwrights and reveals the essence of the "conflict-free theory", which influenced the dramaturgy of that period.

He explains the reason for the revival of national drama after the "Khrushchev's thaw" by the increased attention to stage conventions, to plays written with reference to conventional metaphorical images. The analysis of the qualitative development and change of stage art in this work is carried out in a wide literary context, due to the activities of numerous playwrights who contributed to Tatar dramaturgy during this period (Kh. Vakhit, Yu. Aminov, T. Minnullin, I. Yuzeev, A. Gilyazov, R Mingalim, Z. Hakim, R. Hamid, Yu. Safiullin, M. Karimov, M. Karimov, M. Gilyazov and others). The research is conducted in a comparative aspect (the authors who worked in different periods of Tatar drama based on Russian drama), which allows us to perceive the monograph as the result-conclusion of a certain period of the scholar's activity.

The most significant works of A. Akhmadullin were published in the 1970–1990s. His studies of the work by the major figures of Tatar dramaturgy: G. Kamal, G. Iskhaki, F. Amirkhan, M. Fayzi, K. Tinchurin, F. Burnash, T. Gizzat, N. Isanbet, R. Ishmurat, T. Minnullin and others, laid the foundations for the scientific conception underlying Tatar dramaturgy studies. The scholar continued his research in this direction in his monograph "Tatar Dramaturgy: History and Problems" [9]. "This fundamental work highlights the history of Tatar drama from new ideological and aesthetic positions, evaluates each of the scientific and artistic stages, reveals their features, analyses the most important works that occupy a special place in the history of drama" [10] – writes T. Galiullin. This serious monographic work, based on scientific foundations, studies the trends in the formation and development of Tatar stage literature up to the beginning of the 21st century and emphasizes its main themes and problems, revealing the specifics of each of the development stages and evaluating the numerous works that determined the emergence of Tatar dramaturgy.

A. Akhmadullin's study is an important contribution to scientific research in this area: the scholar, taking into account the specific nature of dramatic scripts as works of both performing arts

and literature, evaluates them based on a synthesis of approaches to the art of theater and literary criticism. Drama as a special kind of literature is studied by scientists in terms of the literary-historical approach as a developing unique integral system. Thus, Azat Akhmadullin created the national conception of the Tatar drama original development [11].

Another aspect of Azat Akhmadullin's lifelong fruitful work is the preparation of highly qualified national personnel who would guide young people on their path of science. The scholar's activity in this direction is mainly connected with the study of certain stages of the drama development, the creative work of the authors who have enriched the performing arts and topical issues of Tatar drama. His first graduate student Nazim Khanzafarov's dissertation on the topic "Naki Isanbet's Dramaturgy" (1975) [12] revealed the essence of the activity of the folklorist who made a great contribution to the Tatar drama development. This work served as the basis for the young scientist's further scientific research. His disciple's monograph "Tatar Comedy (Its Origins and Development)" became his doctoral work, which traced, in a wide literary context, the Tatar comedy development from its classical examples to the end of the 20$^{th}$ century [13]. Prof. Akhmadullin was a scientific supervisor of a number of candidate dissertations by young scholars who entered the scientific arena: L. M. Samigullina [14], G. A. Shakirova [15], L. M. Shaekhova [16], A. S. Sharipova [17]. Their works, which are serious research making conceptual scientific discoveries, are devoted to the complex issues of Tatar dramaturgy, not yet recognized as objects of scientific research. Among the dissertation research, carried out under the guidance of Azat Akhmadullin, are the scientific works devoted to Rizaeddin Fakhrutdinov, a scientist and a writer-educator [18], the prose writer Garif Akhunov [19] and Fail Shafigullin [20].

Another field of the scholar's activity, which attracted the literary community's attention, was his critical work on the issues related to the Tatar art of theater and the literary process as a whole. Not a single new work, seen in Tatar theaters, goes unnoticed by critics: A. Akhmadullin's theater reviews were distinguished by their detailed analysis and meaningful assessments. His reviews were perceived as a chronicle of the Tatar stage life; his comments on various genres and his critical articles, which made a significant contribution to the development of theater criticism, were subsequently published in the form of thematic collections [21], [22], [23].

A. Akhmadullin's great contribution to the preparation of scientific personnel for this significant branch of literary criticism was his scientific supervision of dissertations on the history of Tatar literary criticism and its complex methodological problems. The Ph.D. thesis completed by T. Sh. Gilazov in this area (1992) [24] of scientific research and his active work in subsequent years can be perceived as a new achievement of Tatar literary criticism.

From the 1970s, Azat Akhmadullin was actively engaged in writing textbooks on Tatar literature and creating teaching aids for secondary schools. With the beginning of social transformations, he set about compiling new Tatar literature curricula for the middle and upper classes and gathered a team of authors to write new textbooks; this responsible work was successfully fulfilled. For the years of fruitful work in this area, the scholar was awarded the K. Nasyri Prize of the Tatarstan Republic Ministry of Education in 1999.

Azat Akhmadullin was a member of the Writers' Union of Tatarstan; from 1974 to 1999 he was a member of the Writers' Union Board and its Presidium, for sixteen years he chaired the Board of the Tatarstan branch of the Literary Fund. The laureate of the Zamal Validi Prize of the Union of Writers (2007), Azat Akhmadullin, was devoted to literature and stage art until the end of his life and came a long and fruitful way along this path.

**References**

1. Akhmadullin, A. G. (1963). *Dramaturgiya Fatkhi Burnasha: dissertatsiya ... kandidata filologicheskikh nauk* [Dramaturgy by Fathi Burnash: Ph.D. Thesis]. Kazan', 273 p. (In Russian)

2. Akhmadullin, A. G. (1986). *Zarozhdenie i formirovanie sotsialisticheskogo realizma v tatarskoi dramaturgii: dissertatsiya ... doktora filologicheskikh nauk* [The Origin and Formation of Socialist Realism in the Tatar Dramaturgy: Doctoral Thesis]. Kazan', 385 p. (In Russian)

3. Gilazov, T. (2005). *Literaturnoe nasledie: istoriya i sovremennost'* [Literary Heritage: History and Modernity]. 205 p. Kazan', Tatar.knizh.izd. (In Russian)

4. Akhmadullin, A. G. (1967). *Fatkhi Burnash: zhizn' i tvorchestvo* [Fathi Burnash: Life and Work]. 173 p. Kazan', Tatar. knizh. izd. (In Russian)

5. Akhmadullin, A. G. (1988). *Fatkhi Burnash: zhizn' i tvorchestvo* [Fathi Burnash: Life and Work]. 2 izd. 176 p. Kazan', Tatar. knizh. izd. (In Russian)

6. Akhmadullin, A. G. (1976). *Kak opisat' tebya, Sovremennik?: Ob aktual'nykh problemakh sovremennoi tatarskoi dramaturgii* [How to Describe You, My Contemporary?: On Topical Issues of Modern

Tatar Dramaturgy]. 151 p. Kazan', Tatar. knizh. izd. (In Russian)
7. Akhmadullin, A. G. (1980). *Stsenicheskaya literatura i zhizn'* [Stage Literature and Life]. Literaturno-kriticheskie stat'i. 303 p. Kazan', Tatar. knizh. izd. (In Russian)
8. Akhmadullin, A. G. (2007). *Razbudit serdtsa: sovremennaya tatarskaya dramaturgiya: Monografiya* [Awakening Our Hearts: Modern Tatar Dramaturgy: A Monograph.]. 223 p. Kazan', Tatar. knizh. izd. (In Russian)
9. Akhmadullin, A. G. (2012). *Tatarskaya dramaturgiya: istoriya i problema* [Tatar Dramaturgy: History and Problem]. 511 p. Kazan', Tatar.kn.izd-vo. (In Russian)
10. Galiullin, T. N. (2012). *Slovo ob uchenom i kritike* [A Few Words about the Scholar and the Critic]. Filologiya i kul'tura. Philology and Culture. No. 3 (29), pp. 318-319. (In Russian)
11. Gilazov, T. Sh., Kayumova, G. F. *Naychnaya shkola Azata Gil'mullovicha Akhmadullina* [Scientific School of Azat Gilmullovich Akhmadullin] Filologiya i kul'tura. Philology and Culture. 2022. No. 4(64), pp. 122-129. (In Russian)
12. Khanzafarov, N. G. (1975). *Dramaturgiya Naki Isanbeta: avtoreferat diss. na sois. ... kand. filol. nauk* [Naki Isanbet’s Dramaturgy: Ph.D. Thesis Abstract]. Kazan', 19 p. (In Russian)
13. Khanzafarov, N. g. (1996). *Tatarskaya komediya (Istoki i razvitie): avtoreferat diss. na sois. ... d-ra. filol. nauk* [Tatar Comedy (Its Origins and Development): Doctoral Thesis Abstract]. Kazan', 64 p. (In Russian)
14. Samigullina, L. M. (2004). *Kontseptsii geroya v period zarozhdeniya i stanovleniya tatarskoi dramaturgii (1887-1910): avtoreferat diss. na sois. ... kand. filol. nauk* [Conceptions of the Hero in the Period of the Birth and Formation of Tatar Dramaturgy (1887-1910 Ph.D. Thesis Abstract]. Kazan', 22 p. (In Russian)
15. Shakirova, G. A. (2000). *Dramaturgiya Tufana Minnullina 80-90-kh godov (Tematika i problematika. Zhanrovaya raznovidnost'. Metodika obucheniya v shkole): avtoreferat diss. na sois. ... kand. filol. nauk* [Dramaturgy by Tufan Minnullin in the 1980s and 1990s (Themes and Problems. Genre Variety. Methods of Teaching at School): Ph.D. Thesis Abstract]. Kazan', 19 p. (In Russian)
16. Shaekhov, L. M. (2012).*Tragediya v stikhakh v tatarskoi dramaturgii: zarozhdenie i razvitie: avtoreferat diss. na sois. ... kand. filol. nauk* [Verse Tragedy in Tatar Dramaturgy: the Origin and Development: Ph.D. Thesis Abstract]. Kazan', 22p. (In Russian)
17. Sharipova, A. S. (2007). *Moral'no-ehticheskaya kontseptsiya v dramaturgii Yunusa Aminova: avtoreferat diss. na sois. ... kand. filol. nauk* [Moral and Ethical Conception in the Dramaturgy of Yunus Aminov: Ph.D. Thesis Abstract]. Kazan', 29 p. (In Russian)
18. Dautov, G. (2001). *F. R. Fakhrutdinov-pisatel' i literaturoved: avtoreferat diss. na sois... kand. filol. nauk* [Fakhrutdinov as a Writer and Literary Critic: Ph.D. Thesis Abstract]. Kazan', 19 p. (In Russian)
19. Gaifullina, F. A. (2003). *Proza Garifa Akhunova (ehvolyutsiya tvorchestva): avtoreferat diss. na sois. ... kand. filol. nauk* [Garif Akhunov’s Prose (evolution of his creative work): Ph.D. Thesis Abstract]. Kazan', 26 p. (In Russian)
20. Shafigullina, R. F. (2000.). *Kontseptsii lichnosti v tvorchestve Failya Shafigullina: avtoreferat diss. na sois. ... kand. filol. nauk* [The Concept of Personality in Fayil Shafigullin’s Work: Ph.D. Thesis Abstract`]. Kazan', 19 p. (In Russian)
21. Akhmadullin, A. G. (1993). *Na puti k spravedlivosti* [On the Way to Justice]. Stat'i. 255 p. Kazan', Tatar. knizh. izd. (In Russian)
22. Akhmadullin, A. G. (2002). *Kogda rasshiryayutsya gorizonty* [When Horizons Expand]. Literaturno-kriticheskie stat'i. 239 p. Kazan', Tatar. knizh. izd. (In Russian)
23. Akhmadullin, A. G. (2018). *Na puti vozrozhdeniya* [On the Way to Revival]. Nauchnye stat'i. 206 p. Kazan', Tatar. knizh. izd. (In Russian)
24. Gilazov, T. Sh. (1992). *Osnovnye tendentsii razvitiya tatarskoi literaturnoi kritiki v 20-30-e gody (problema metoda i geroya): avtoreferat diss. na sois. ... kand. filol. nauk* [The Main Development Trends of Tatar Literary Criticism in the 1920s and 1930s (the problem of method and hero): Ph.D. Thesis Abstract]. Kazan', 25 p. (In Russian)

# КҮРЕНЕКЛЕ ӘДӘБИЯТ ГАЛИМЕ АЗАТ ГЫЙЛЬМУЛЛА УЛЫ ӘХМӘДУЛЛИН

**Флера Сәгыйть кызы Сәйфулина,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
fsaifulina@mail.ru

Татар җәмәгатьчелегендә Азат Гыйльмулла улы Әхмәдуллин (1932–2021) – әдәбият галиме, сәхнә сәнгате белгече һәм тәнкыйтьче, татар драматургиясе тарихын концептуаль нигездә

өйрәнеп, татар әдәбият белеме фәненең әлеге юнәлешендә үзенең фәнни мәктәбен булдырган остаз, педагог-методист буларак танылу алган зыялы шәхес.

Азат Әхмәдуллин 1932 елның 13 октябрендә Татарстанның Саба районы Байлар Сабасы авылында дөньяга килә. Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, бер ел Шекше авылы җидееллык мәктәбендә физика һәм математика укыта. 1951–1956 елларда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә югары белем ала, аны кызыл диплом белән тәмамлый. Берникадәр вакыт Татарстан китап нәшриятының фәнни-техник әдәбият редакциясендә мөхәррир булып эшли.

Педагогик эшчәнлеген Төмән өлкәсенең Тубыл (Тобольск) дәүләт педагогия институтында башлап җибәрә, монда 1956–1958 елларда студентларга белем бирә. Ике ел югары мәктәп системасында эшләгән Азат Әхмәдуллин Казанга киләчәк тормышын әдәбият фәне белән бәйләү турындагы ныклы карар белән кайта. 1958–1961 елларда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалында аспирантурада укый, аны тәмамлагач, Татарстан Радиокомитетында әдәби-сәнгать тапшырулары бүлегенең баш мөхәррире булып эшли.

Азат Гыйльмулла улының гыйльми-педагогик эшчәнлеге нигездә Республиканың татар фәнен үстерү һәм милли кадрлар әзерләү юнәлешендәге өч оешма: ТР Фәннәр Академиясенең Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Казан дәүләт университеты, Казан дәүләт педагогия институтлары белән бәйләнгән.

Фәнни эшчәнлеген А. Әхмәдуллин 1963 елда Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм тарих институтында (хәзер: Тел, әдәбият һәм сәнгать) кече гыйльми хезмәткәр буларак башлый, 1964 елда М. Х. Гайнуллин җитәкчелегендә «Фәтхи Бурнаш драматургиясе» [1] дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый һәм өлкән гыйльми хезмәткәр вазифасында эшен дәвам итә. Монда яшь галимнең фәнни эшне оештыру сәләте ачыла: ул 1965 елдан институтның гыйльми сәркәтибе, 1972 елдан институт директорының фәнни эшләр буенча урынбасары булып эшли.

А. Әхмәдуллин 1981 елда Казан дәүләт университетына татар әдәбияты кафедрасының мөдире итеп эшкә күчерелә һәм 1999 елга кадәр эшли. 2000 елдан алып лаеклы ялга киткәнче (2012), Казан дәүләт университетының (2011 елдан Казан федераль университеты) татар әдәбияты кафедрасы профессоры. 1999–2004 елларда Казан педагогия университетында белем бирү белән бергә 2000–2004 елларда татар әдәбияты кафедрасы мөдире вазифасын да башкара.

Азат Гыйльмулла улы 1987 елда Казахстанның Фәннәр Академиясендә (Алма-Ата шәһәре) татар драматургиясенең үсеш этаплары һәм үзенчәлекләрен өйрәнүгә багышланган докторлык диссертациясен яклый [2], 1988 елда профессор дәрәҗәсен ала. 1994 елда Татарстан Фәннәр Академиясенең мөхбир әгъзасы итеп сайлана.

А. Әхмәдуллин – хаклы рәвештә татар сәхнә сәнгатен фәнни нигездә өйрәнү юнәлешен башлаучы дип санала. Галимнең төп гыйльми хезмәтләре татар драматургиясе үсешен концептуаль нигездә системалы рәвештә өйрәнүгә багышланган. Күренекле драматург Фәтхи Бурнаш иҗатын монографик планда өйрәнүдән башланган тикшеренүләр галимне әдәбият фәненә алып керә. «Һәр иҗат кешесенең әдәби-гыйльми эшчәнлеген бер үзәк тирәсенә җыя, җан җылысы белән яратып эшли торган өлкәсе була, – дип яза Т. Гыйлаҗев. – Әлеге зыялы затның бер-берсен тулыландыручы ике фәнни юнәлешен билгеләргә мөмкин. Аның берсе – Ф. Бурнаш иҗатын барлау һәм өйрәнү, икенчесе – татар драматургиясе» [3, 198 б.]. Шушы хезмәттән башлап, татар әдәбияты тарихын өйрәнүгә зур өлеш керткән күренекле татар әдәбияты галиме дәрәҗәсенә ирешкәнче, Азат Гыйльмулла улы фәнни ачышлардан торган олы тормыш юлы уза. Ф. Бурнаш иҗатына галим кат-кат әйләнеп кайта, XX гасырның 40 елларына кадәр драматургия, шигърият, проза, публицистика, тәрҗемәчелек өлкәсендә күпкырлы эшчәнлек алып барган катлаулы язмышлы шәхес иҗатын өйрәнү һәм исемен әдәбиятка кайтару юнәлешендә күп эш башкара [4], [5].

Галимнең 1960–1980 елларда татар театр сәнгате үсеше, драматургиянең актуаль мәсьәләләренә багышлап язылган күпсанлы фәнни мәкаләләре аерым җыентыклар булып дөнья күрә [6], [7]. Алардагы әдәбиятның әлеге үзенчәлекле жанрында эшләүче драматурглар иҗатындагы яңалык-үзенчәлекләр, замана героен сәхнә әсәрендә тудыру алымнары, тормыш дөреслеге һәм аның әдәби әсәрдә тергезелүе, сәхнә жанрлары кебек актуаль мәсьәләләргә мөнәсәбәтле фикерләр чор драматургиясенең сыйфат үсешен күзалларга мөмкинлек бирә.

XXI гасыр башында дөнья күргән «Күңелләрне уятыр: Хәзерге татар драматургиясе» монографиясендә (2007) [8] галим XX гасырның икенче яртысы татар драматургиясен киң планда, милли сәхнә сәнгатен бербөтен процесс рәвешендә өйрәнә. Әлеге саллы хезмәттә автор совет җәмгыятендә хөкем сөргән хәлләрнең асылын ачкан, сәнгать дөреслегенә ирешү юнәлешен чагылдырган әсәрләрнең узган гасырның 60–70 елларында ук башлануын нигезле дәлилләр белән раслый. «Торгынлык чоры» дип бәяләнгән катлаулы чор драматургиясендә формалашкан «герой эзләү проблемасы» тенденциясен аерып чыгарып, аны шул заманның күренекле драматурглары әсәрләрендәге иҗади эзләнүләр һәм аерым табышлар аша раслый, әлеге чор драматургиясенә тәэсир иткән «конфликтсызлык теориясе»нең асылын ача.

«Хрущев җепшеклеге»ннән соң милли драматургиядәге җанлануның сәбәбен сәхнә шартлылыгына, шартлы-метафорик образларга мөрәҗәгать итеп язылган пьесаларга игътибар арту белән аңлата. Әлеге хезмәттә сәхнә сәнгатендәге сыйфат үсеш-үзгәреше галим тарафыннан киң әдәби контекстта, шушы чор татар драматургиясенә өлеш керткән күпсанлы драматурглар эшчәнлеге аша (Х. Вахит, Ю. Әминов, Т. Миңнуллин, И. Юзиев, А. Гыйләҗев, Р. Мингалим, З. Хәким, Р. Хәмид, Ю. Сафиуллин, М. Гыйләҗев һ.б.) чагыштырма аспектта (татар драматургиясенең төрле чорларында иҗат иткән авторлар иҗаты, рус драматургиясе мисалында) ача һәм бу монографияне галим эшчәнлегенең аерым бер чорына нәтиҗә-йомгак төсендә кабул итәргә мөмкинлек бирә.

А. Әхмәдуллинның иң әһәмиятле хезмәтләре 1970–1990 еллар арасында дөнья күрә. Аның татар драматургиясенең үзәк фигуралары булган Г. Камал, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, М. Фәйзи, К. Тинчурин, Ф. Бурнаш, Т. Гыйззәт, Н. Исәнбәт, Р. Ишморат, Т. Миңнуллин һ.б. иҗаты буенча киңкырлы эзләнүләре татар драматургиясен өйрәнүнең фәнни концепциясенә нигез сала. Бу юнәлештәге системалы эшчәнлеге галимнең «Татар драматургиясе: тарих һәм проблемалар» (2012, рус телендә, «Татарская драматургия: история и проблемы» [9] монографиясендә урын алды. «Бу фундаменталь хезмәттә татар драматургиясе тарихы яңа идея-эстетик карашлардан чыгып яктыртыла, фәнни-сәнгати этапларның һәрберсенә бәя бирелеп, үзенчәлекләре ачыла, драматургия тарихында үзенчәлекле урын алган мөһим әсәрләргә анализ ясала» (сүзгә-сүз тәрҗемә. – *Ф. С.*) [10] – дип яза Т. Галиуллин. Җитди монографик хезмәттә татар сәхнә әдәбиятының формалашу һәм үсеш тенденцияләре XXI гасыр башына кадәр фәнни нигездә өйрәнелә; төп тема һәм проблемалары ассызыклана, үсеш этапларының һәрберсенең үзенчәлеге ачыклана; татар драматургиясенең йөзен билгеләүче күпсанлы әсәрләргә бәя бирелә.

А. Әхмәдуллин хезмәтләренең фәнни әһәмияте шуның белән билгеләнә: галим драма әсәрләренең бер үк вакытта сәхнә сәнгате дә, әдәби әсәр дә буларак үзенчәлекле табигатен исәпкә алып, аларны бәяләгәндә, театр сәнгате һәм әдәбият белеме өлкәсенә кагылышлы карашлар синтезында эш итә. Әдәбиятның үзенчәлекле төре буларак драма галим тарафыннан үсештә булган үзенчәлекле бербөтен система буларак әдәби-тарихи яссылыкта өйрәнелә. Азат Әхмәдуллин, шул рәвешле, татар драматургиясенең оригиналь үсеше турында милли тәгълимат булдыра [11].

Азат Гыйльмулла улының күпъеллык нәтиҗәле эшенең тагын бер юнәлеше – яшьләрне фән юлына алып кереп, югары квалификацияле милли кадрлар әзерләүдән гыйбарәт. Галимнең әлеге юнәлештәге эшчәнлеге дә, нигездә, драматургиянең аерым үсеш этапларын, сәхнә сәнгатен баеткан аерым шәхесләр иҗатын, татар драматургиясенең актуаль мәсьәләләрен өйрәнү белән бәйле. Беренче аспиранты Назим Ханзафаровның «Нәкый Исәнбәт драматургиясе» (1975) [12] темасына язылган диссертациясе татар драматургиясе үсешенә зур өлеш керткән фольклорчы-галимнең бу өлкәдәге эшчәнлегенең асылын ача һәм яшь галимнең киләчәктәге фәнни эзләнүләренә төпле нигез дә булып тора. Шәкертенең татар комедиясенең классик үрнәкләрдән алып XX гасырның ахырына кадәрге үсешен киң әдәби контекстта күзәткән «Татар комедиясе (тамырлары һәм үсеше)» монографик хезмәте дә, А. Әхмәдуллинның хәерхаклы фатихасы белән дөнья күрә, докторлык эшенә әверелә [13]. Галим җитәкчелегендә бер-бер артлы фән аренасына чыккан яшьләрнең кандидатлык диссертацияләре дә (Л. М. Сәмигуллина [14], Г. Ә. Шакирова [15], Л. М. Шәехов [16], А. С. Шәрипова [17]) – татар драматургиясенең әлегә кадәр фәнни эзләнү объекты итеп алынмаган катлаулы мәсьәләләрен ачыклауга багышланган,

үзәгендә житди эзләнүләр һәм концептуаль фәнни ачышлардан торган хезмәтләр. Азат Әхмәдуллин житәкчелегендә башкарылган диссертацион эзләнүләр арасында галим һәм мәгърифәтче язучы Ризаэддин Фәхретдинов [18], прозаик Гариф Ахунов [19], Фаил Шәфигуллин [20] эшчәнлегенә багышланган фәнни хезмәтләр дә бар.

Галим эшчәнлегенең әдәби җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп иткән тагын бер тармагын – татар театр сәнгате, гомумән, әдәби барыш белән бәйле мәсьәләләргә кагылышлы тәнкыйди эшчәнлеге тәшкил итә. Татар театрларында дөнья күргән һәрбер яңа әсәр тәнкыйтьче карашыннан читтә калмый: А. Әхмәдуллинның театр рецензияләре тәфсилле анализ, төпле бәя белән аерылып тора. Аның бәяләмәләре татар сәхнә тормышының елъязмасы кебек кабул ителә; театр тәнкыйтен үстерүгә әһәмиятле өлеш керткән төрле жанрлардагы язмалары, тәнкыйди мәкаләләре алга таба тематик җыентыклар булып дөнья күрә [21], [22], [23].

Галим җитәкчелегендә татар әдәби тәнкыйте тарихы, аның катлаулы методологик проблемаларына багышланган диссертация язылу – А. Әхмәдуллинның әдәбият гыйлеменең әлеге әһәмиятле тармагы өчен фәнни кадрлар әзерләү юнәлешенә керткән зур өлеше буларак бәяләнә. Т. Ш. Гыйлаҗевның бу юнәлештә башкарылган кандидатлык диссертациясе (1992) [24] һәм аннан соңгы еллардагы актив эшчәнлеге – татар әдәбият гыйлемендә яңа сүз буларак кабул ителә ала.

Азат Әхмәдуллин узган гасырның җитмешенче елларыннан бирле урта мәктәпләр өчен татар әдәбиятыннан дәреслекләр язу, уку-укыту әсбаплары төзү өлкәсендә дә актив эшли. Җәмгыятьтә үзгәртеп кору чоры башлангач, ул урта һәм югары сыйныфлар өчен татар әдәбиятыннан яңа уку программалары төзүгә алына, яңа дәреслекләр язу өчен авторлар коллективы туплап, бу җаваплы эш белән уңышлы җитәкчелек итә. Бу өлкәдәге күпъеллык нәтиҗәле хезмәте 1999 елда ТР Мәгариф министрлыгының К. Насыйри исемендәге премия белән бәяләнә.

Азат Гыйльмулла улы Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, 1974 елдан 1999 елга кадәр Язучылар берлеге идарәсе һәм аның президиумы әгъзасы, уналты ел буена Әдәбият фондының Татарстан бүлеге идарәсе рәисе булып эшли. Язучылар берлегенең Җамал Вәлиди исемендәге премия лауреаты (2007) Азат Әхмәдуллин гомеренең ахырына кадәр әдәбият фәненә, сәхнә сәнгатенә тугрылыклы булды һәм шушы юлда игелекле һәм югары нәтиҗәле юл узды.

**Әдәбият**


1. *Ахмадуллин А. Г.* Драматургия Фатхи Бурнаша: дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1963. 273 с.
2. *Ахмадуллин А. Г.* Зарождение и формирование социалистического реализма в татарской драматургии: дис. ... докт. филол. наук. Казань, 1986. 385 с.
3. *Гыйлаҗев Т.* Әдәби мирас: тарих һәм заман. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 205 б.
4. *Әхмәдуллин А. Г.* Фәтхи Бурнаш: тормыш юлы һәм иҗаты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1967. 173 б.
5. *Әхмәдуллин А. Г.* Фәтхи Бурнаш: тормыш юлы һәм иҗаты. 2 басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. 176 б.
6. *Әхмәдуллин А. Г.* Ничек сурәтләргә сине, замандаш?: Бүгенге татар драматургиясенең актуаль проблемалары турында. Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. 151 б.
7. *Әхмәдуллин А. Г.* Сәхнә әдәбияты һәм тормыш. Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар.кит.нәшр., 1980. 303 б.
8. *Әхмәдуллин А. Г.* Күңелләрне уятыр: Хәзерге татар драматургиясе: Монография. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. 223 б.
9. *Ахмадуллин А. Г.* Татарская драматургия: история и проблемы. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. 511 с.
10. *Галиуллин Т. Н.* Слово об ученом и критике // Филология и культура. Philology and Culture. 2012. № 3 (29). С. 318–319.
11. *Гилазов Т. Ш., Каюмова Г. Ф.* Научная школа Азата Гильмулловича Ахмадуллина. Филология и культура. Philology and Culture. 2022. №4(64). С. 122–129.
12. *Ханзафаров Н. Г.* Драматургия Наки Исанбета: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1975. 19 с.
13. *Ханзафаров Н. Г.* Татарская комедия (Истоки и развитие). автореф. дис. ... докт. филол. наук. Казань, 1996. 64 с.
14. *Самигуллина Л. М.* Концепция героя в период зарождения и становления татарской драматургии (1887–1910): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2004. 22 с.
15. *Шакирова Г. А.* Драматургия Туфана Миннуллина 80–90-х годов (Тематика и проблематика. Жанровая разновидность. Методика изучения в школе): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2000. 19 с.
16. *Шаехов Л. М.* Трагедия в стихах в татарской драматургии: зарождение и развитие: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2012. 22 с.

17. *Шарипова А. С.* Морально-этическая концепция в драматургии Юнуса Аминова: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2007. 29 с.

18. *Даутов Г. Ф.* Р.Фахрутдинов – писатель и литературовед: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2001. 19 с.

19. *Гайфуллина Ф. А.* Проза Гарифа Ахунова (эволюция творчества): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2003. 26 с.

20. *Шафигуллина Р. Ф.* Концепция личности в творчестве Фаиля Шафигуллина: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2000. 19 с.

21. *Әхмәдуллин А. Г.* Дөреслеккә ирешү юлында. Мәкаләләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. 255 б.;

22. *Әхмәдуллин А. Г.* Офыклар киңәйгәндә. Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. 239 б.

23. *Әхмәдуллин А. Г.* Яңарыш юлында: фәнни мәкаләләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. 206 б.

24. *Гилазов Т. Ш.* Основные тенденции развития татарской литературной критики в 20-30-е годы (проблемы метода и героя): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1992. 25 с.